ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 15 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 86 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:

а) 1 өлештә:

өченче абзацта «республика программаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа кырык өченче абзац өстәргә:

«әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру;»;

кырык өченче абзацны кырык дүртенче абзац дип санарга;

б) 2 өлештә «кырык өченче» сүзләрен «кырык дүртенче» сүзләренә алмаштырырга;

2) 50 статьяда:

а) 1 өлештә «Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) күрсәткечләренең дәүләт фондын төзү һәм аннан

файдалану» сүзләрен «әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасын төзү, аннан файдалану һәм аны үстерү» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасындагы өченче – бишенче абзацлары һәм «б» пунктчасы 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 февраль
№ 3-ТРЗ